ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

# КАРАР

“10” декабрь 2024 ел № 26

**Арча муниципаль районы "Яңа Кишет авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Яңа Кишет авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уставы, "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2022 елның 08 августындагы 55 номерлы Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карары нигезендә, 12.11. 2024 N5, 13.11. 2024 N6, 14.11. 2024 N7, 14.11. 2024 N8, җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатыннан, Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы "Яңа Кишет авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: ТР, Арча районы, Яңа Кишет авылы, Дуслык ур., 100а йорты, ТР, Арча районы, Иске Кишет авылы, Г.Сафиуллин ур., 26а йорты, ТР, Арча районы, Кышкар авылы, Яңа ур., 125 йорт, ТР, Арча районы, Симетбаш авылы, Үзәк ур., 19а йорты.

3. "Яңа Кишет авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында" 2023 елның 14 декабрендәге 35 номерлы Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны өстемә алам.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Ф.И.Ахмадуллин

Яңа Кишет авыл җирлеге
башкарма комитетының
10 декабрь 2024 ел. №26
карарына кушымта

**Арча муниципаль районы "Яңа Кишет авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Арча муниципаль районы "Яңа Кишет авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын Арча муниципаль районы "Яңа Кишет авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә нинди мөнәсәбәттә булуларына карамастан, 2024 елның 16 февраленә кадәр түлиләр.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары (бергә яшәүче ата-аналар, ир яки хатын, балигъ булган балалар).

4. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а) көндезге бүлектә белем алучы студентлар,

б) 1 төркем инвалидлар,

в) 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен түләүләр күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

5. Нигезле сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының (ата-анасының, иренең/хатынының, балаларының) вафат булуы,

б) янгын яисә башка табигый бәла-казалар аркасында зыян килү гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан да артмаган вакытка кичектерү бирелә.

6. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында гражданнарга хәбәр итү бланкы (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгару, Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру, шулай ук кул куеп тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләүнең тулы яисә киметелгән күләме, аны түләү срогы булырга тиеш.

7. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Арча муниципаль районы "Яңа Кишет авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

8. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча акча күчерү юлы белән башкарыла.

9. Түләү фактын приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслый торган башка документлар раслый.

10. Гражданнарның үзара салым акчалары билгеләнгән вакытта кертелмәгәндә, алар законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Яңа Кишет авыл җирлеге
башкарма комитетының
10 декабрь 2024 ел, №26
карарына 2 нче кушымта

**Яңа Кишет авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә N ____________**

Түләүченең Ф.И.А.и________________________________________

Адресы:________________________________________________

Нигезе_________________________________________________

Сезгә __________________ чараларны гамәлгә ашыруга бер тапкыр түләү______________________________ суммада ___________ сум түләргә кирәк.

түбәндәге реквизитлар буенча:____________________________________

алучының банкы БИК ______________________

Сч. N ________________________________

Алучы Сч. N ________________________

ИНН ____________________________________

КПП ____________________________________

КБК _____________ОКАТО _______________

Түләүнең билгеләнеше __________________________________________________

Җитәкче ______________ ________________________________

М. у. (имза) (имзаның аңлатмасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисем сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

"Яңа Кишет авыл җирлеге"муниципаль берәмлегендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне түләү турында хәбәрнамә №__
суммада _______________ сум

Түләүченең Ф. и.а.и. ________________________________________

Адресы: _____________________________________________

Алдым "__" _____________ 20__ ел ______________________________

(түләүченең имзасы /ФИАи)

Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өзек тамыр тутырыла һәм Яңа Кишет авыл җирлеге Башкарма комитетында кала